بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَانِ الرَّحِيمِ

“Әмирханийә” мәгърифәтчелек вәкыфы

Илдус Әмирхан

# АЛТЫН МИЛЛИАРД ФЕТНӘСЕ

## (яки дөньяга террор белән кем яный)

Казан 2012 йыл

## «Алтын миллиард» фетнәсе
### *яки дөньяга террор беләң кем яный*

«Шәһри Казан» гәзитенең 2002 йыл 26 март санында күренекле татар галиме академик Мирза ага Мәхмүдевнең «Ислам яклауга мохтаҗмы?» дигән зур күләмле мәкаләсе басылган иде. Анда хөрмәтле галимебез татарлар арасында беренчеләрдән булып «террорчылыкка каршы көрәш» уйдырмасы астында исламга каршы дөньякүләм алып барылган хөҗүмнең асылын ачыклау максатын куйган. Бу мәкалә, гомумән алганда, ислам дөньясына гына түгел, татар халкының да киләчәк язмышына кагылганлыктан, мин аны игътибарсыз калдыра алмадым. Мирза аганың фикерләренә куәт бирү, динебезне һәм милләтебезне яклау максатынан әлеге язмамны җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим итәсем килә.

Мирза ага Мәхмүдевны, үзе әйтүе буйынча, бу мәкаләне язуга Казанда туып, Америкада йәшәп ятучы язучы (хәзерге вакытта ул Францийәгә күчеп киткән, ни әйтсәң дә, ул «дөнья кешесе») Аксеновның 2001 йыл 11 сентябрь вакыйгаларына (Нью Йорк, Вашингтон фаҗигаләре) бәйләнешле «Койрык болгаудан туктарга вакыт» дигән мәкаләсе этәргән. Әлеге мәкаләне мин дә укыган идем. Тик аңа бөтендөнья мәгълүмат чаралары аша барлык телләрдә дә көне-төне алып барылган исламга каршы пропаганданың айырым бер чагылышы итеп кенә карадым. Мирза ага алай уйламаган ахры. Җавап бирүне кирәк тапкан. Һәм дөрес иткән. Чыннан да, эш бер Аксенов мәкаләсендә генә булса, әллә ни борчыласы урын да юк иде. Әмма Татарстан туфрагында исламга каршы нәфрәт туплап яткан бу урыс жыһуды (жидорус) бүгенге көндә ойышып, формалашып килгән дөньякүләм көфер көчләрнең актив сүзчесе. Әлеге фикерләрен ул зур урын биләгән сәйәсәтчеләрдән айырмалы буларак, ачыктан-ачык белдерә. Ислам каршында койрык болгаудан туктарга, аны юк итәргә кирәк, ди. Ягъни, икейөзлек битлеген алып ташларга һәм исламны икеләнүсез кешелек дөньясының дошманы итеп игълан итәргә. «Комсомольская правда»га биргән бер интервьюсында да ул дөньяны бетерү куркынычы белән янаган коммунизмга алмашка ислам идеологийәсе килә ди. Террорчылык кына да түгел, ислам куркынычы! Моны ул басым ясап әйтә. Шуңа күрә Русия халкын да исламга каршы аяусыз көрәшкә чакыра. Әлбәттә, мондый чакырулар ислам дошманнарын тагы да канатландыра. Аксенов фикерен куәтләүчеләр “Эхо Москвы”, «Свобода», «Би-би-си», «Немецкая волна» кебек «ирекле» радиостанцийәләрдә дә өстенлек итә башлады. «Свобода» радиосы үзенең кайбер көндәлек тапшыруларын бер Русийә сәйәсәтчесенең: «Да, мы плохое правительство, да, мы нарушаем права человека. Но видете же, исламисты наступают – или они или мы!» диган чакыруы белән башлый. Инде безнең «Азатлык» та «террорга каршы» көфер дөньясы фикерләрен татар һәм башкорт телләрендә яңгырата. Һәм бу йүнәлештә көннән-көн активлаша. Хуҗалары басым ясый булса кирәк. Нишлисең бит, чит табыннан туйынганда, ашка таш белән атып булмый. Чөнки татарның үзенең мөстәкыйль мәгълүмат чаралары юк һәм булырга да ошамаган. Ул һаман да йә Мәскәү сүзен сөйләргә, йә Америка көйен көйләргә

мәҗбүр. Ә ислам дөньясына каршы нәфрәт таратучы «Радио России», «Русское радио», «Маяк» кебек гомумрәсәй радиолары турында әйтәсе дә юк. Алар ярты сәгать сайын «ислам экстремистларының», «ислам террорчыларының» «җинаятьчел» эшләрен, «явыз» нийәтләрен бертавыштан дийәрлек «фаш» итеп торалар.

Ә иң аянычы шул, бу «фаш» итүләр үзләренең тискәре нәтиҗәләрен бирә дә башлады инде. Чөнки даими алып барыла торган пропаганда никадәр ялган булмасын, ул кеше аңның иң тирән катламнарына сеңә бара һәм берникадәр вакыттан кире кайтмаслык һәм тотрыклы инануга әйләнә. Бу пропаганда кануны. Ул бүгенге шартларда бигрәк тә нәтиҗәле. Чөнки мәгълүмат чаралары аркылы массаларга тәэсир итү технологияләре көннән-көн камилләшә бара.

Бу тәссирнең нәтиҗәлелеге татар аңында да сизелә. Әле бит күптән түгел генә без үзебез дә мөстәкыйльлек даулап, «азатлык» дип кычкырып йөргән идек. Әллә ни зур таләпләр куймасак та, Мәскәүнең бөтен шовинистлары дәррәү басты. Татарстаннан җәһәннәм чокыры ясап, аны Рәсәйнең үзәгендә хасил булган шартлау өйермәсе итеп сүрәтләделәр. Казан диварлары «Это - Россия» дигән язмалар белән тулды. «Вечерняя Казань», «Казанский телеграф» кебек карагруһ гәзитләр милли хәрәкәтне мыскыл иттеләр. Сары сакаллы манкорт «демократлар» татар халкына пычрак аттылар. Аның милли әйдәрләреннән карачкы ясадылар. Мәскәүнең матбугат чаралары дөнья бетәрдәй кылана башлады. Ул гына җитмәде, безне Монголийәгә куу белән янарга керештеләр. Бу бер «тиле» сәйәсәтченең генә фикере түгел, Мәскәү «демократларның» да нийәте иде. Татарстан илбашы өчен Пугач читлеген хәстәрләргә керештеләр.  Кулында ук та булмаган татарга танк көпшәсен төзәделәр. Инде аяк-кулларыбызга богау салып, муйыныбызга «бандит» тамгасы тагып, мал вагоннарына төйәп җәһәннәмгә озатасы гына калган иде.

Шуларны бик тиз оныттык булса кирәк. Күпләр бу халәтнең булганына ышанмый. Чөнки алар Мәскәү вәхшилеге белән күзгә-күз очрашмаган. Син кол, юаш сарык булганда: «какой хороший татарчонок», дип башыңнан сыйпаган маржаларның, аз гына ирекකә дәгъва  белдергәндә явызларча ыржаюларын күрмәгән. Ә без күргән, чөнки алар белән, йөзгә-йөз килеп ирек даулаган, читлек аша «сайрашып гомер кичерүдән», телен тешләүдән баш тарткан.

Шулай да татар тулысынча «бандит» булып җитешмәде. «Ийелгән башны кылыч кисми» дип, Мәскәү түрәләре каршында баш иде. Чөнки бу «явызлык үзәге»  «күз йәшләренә ышанмый», аңа ике генә нәрсә – йә кан бирмәк, йә кол итмәк кирәк. Без каныбызны кызганып, коллык сайладык. «Бандит», «вәһһабит», «террорист» буласы урынга «цивилизованный татарга» әйләндек. Инде ирекකә омтылышның соңгы җепселләрен кисәләр. Чөнки Мәскәү ул татар түгел, аның кылычы ийелгән башны да кисә. Һаман да татар башының күтәрелүеннән курка. Тапталганда да тәгәрмәчкә үрелгән «татарник» аңа тынгылык бирми.

Ә чечен халкы баш ийеп кол буласы килмәде. Русийә биргән ике мөмкинлекнең иң хәтәрен сайлады. Ирек биргәнче, кан бирүне өстен күрде. Әле дә бер чечен сугышчысының сүзләрен хәтерлим. Ул автоматын өскә күтәреп: «Без җиңсәк, җирдә ирекле, җиңелсәк - ахирәттә җәннәтле булабыз», - дигән иде.

Хәйер, ирекකә омтылыш дөньядагы бар мәхлукатка да хас. Чөнки аларның

барысы да фитрый иман белән ярала. Чәнечкесе, агуы, теше, тырнагы белән ireгеn саклый. Үлсә үлә, әмма буйсынмый. Буйсыну халәте табигатен бозудан килә. Бүреләрнең эткә әйләнүләрен Зиннур Әһлиуллин язып чыккан иде инде. Ә менә барлык мәхлукатның патшасы булган адәм баласының колга әйләнүен язарга ашыкмыйбыз. Чөнки барыбыз да бүредән эткә әйләнеп барабыз. Хәтта монда да бүләләр: өй, йорт, урам этләренә. Хуҗаларыбызны яклап, бер беребезгә өрәбез.

Ирекнең һәр мәхлукатка нинди татлы икәнлеген бер генә мисалда күрсәтәсем килә. Күп йыллар элек авыл мәктәбендә эшләгәндә, балалар кышкы урманнан ниндидер җәнлек алып кайттылар (исеме хәтердән чыккан). Чирле булган булса кирәк. Шуннан аны футбол кыры кадәр спортзалга җибәрдек. Төрле ризык-ашамлык бирдек. Җылы, тук булсын дидек. Икенче көнне килеп карасак, ник бер азыкка тотынсын. Янына килә башласаң, аякларын күтәрә дә, әче итеп кычкыра. Ярар дибез, бәлки бер-ике көндә ияләшер. Кая ул! Бер почмакка поскан да - ашамый да, эчми дә, селкенми дә, якын да җибәрми. Мин инде эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, балаларга аны кире урманга җибәрергә куштым. Алар шулай итте дә. Кулдан ычкынуга, бар фәрманга, карга бата-чума урманга йөгерә. Ач, хәлсез килеш. Балалар артыннан ийәргән сайын, җәһәтрәк чаба. Ниһайәт урманга кереп югалды. Ә анда аны нәрсә көтә? Кар, суык, ачлык! «Менә, - дим, балаларга, - ирек дигән нәрсә нинди татлы икән. Үлем куркынычы да аның ләззәтен киметә алмый». Җәнлек түгел, хәтта зәгыйфь тал чыбыгы да ирексез бөгелергә теләми, сынса-сына, әмма турайырга, элекке халәтенә кайтырга тырыша.

Димәк, бөтен табигать, бар мәхлукат энә кадәр үсентедән алып, күккә тийеп торган наратка, күзгә күренмәс бөҗәктән алып, урман патшасы юлбарыска кадәр үз ирееn, үз нәселен, үз токымын җанын фида итәрдәй дәрәҗәдә саклый.

Без исә, табигатьнең таҗы дип аталган адәм балалары, Салтыков Щедринның акыллы ташбашы кебек, ком астыннан башыбызны чыгарып, «акылсыз» «террорчыларны» сүгеп, «ислам тынычлык дине» дигән булып, иблис тегермәненә су койып ятабыз. Инде ничә кабат утлы табада кыздырылсак та, валчык кадәр җимгә дә кабарга торабыз. Йә Ходай, ник без мондый түбәнлеккә төштек соң?!

Колны без аякка богау салган, муйынга камыт таккан бәндә рәвешендә күз алдына китерергә күнеккәнбез. Ә менә тәхеттә утыручы, зиннәтле йортларда йәшәүче, затлы машинада йөрүче, һәр тарафка фәрман биреп кенә торучы бәндәне ирекле саныйбыз. Бай алдында, гафу итегез, ыштан салабыз, ярлы каршында этәч булып кычкырабыз. Ә чынлыкта исә, бөтенләй киресе булуы мөмкин. Чөнки ирек һәм коллык ул тышкы сыйфат түгел, эчке халәт. Иман булганда, син зинданда да ирекле, ә булмаганда - тәхеттә да кол. Үзен бик ирекле, гадел һәм туры сүзле санаган бер ханымга шушы сүзләрне әйткәч, ул миңа кинайәле йылмайып: «юк инде, мин тәхеттә утыруны зинданда утырудан өстенрәк күрәм», - дигән иде.

Шунда бүгенге «цивиль» татарның ирекле халыктан айырмасы да. Кол тәкәбберлеге белән илаһи ирек икесе ике нәрсә. Бер акыл ийәсенең шундый әйтеме истә калган: «Лишь тот достоин счастья и свободы, кто каждый день идет за них на бой!». Безнеңчә әйтсәк, даими җиһадта булган кеше генә ирекккә лайыклы.

Шул уңайдан бер мисал китерәм. Миңа җитмешенче йыллар башында

Мәскәүнең Үзәк нефть институтында дүрт йыл чамасы Исраил хөкүмәте рәисе урынбасары булып эшләгән Натан Шаранский белән бергә эшләргә туры килде. Миннән биш йәшкә кече булса да, гайәт дәрәҗәдә укымышлы, мәгълүматлы кеше иде. Ул вакытта ук диссидент исемен күтәреп йөрде. Аңа кушылып китмәсәк тә, күп кенә сүзләренә колак сала идек. Торгынлык йыллары, милли кимсенү тойгысы җанга ирек сорый иде. Кеше хокуклары, демократийә, ирекле җәмгыйәт хакында тәүге мәртәбә без аңардан ишеттек. Үзебез дә берникадәр дәрәҗәдә демократ булып киттек. Казанга кайтып милли һәм демократик хәрәкәткә кушылып китүгә дә бәлки шуның йогынтысы булгандыр. Әмма Казанда вакытта аның кулга алынып, 13 йылга иректән мәхрүм ителүен ишеттем. Борчылып Мәскәүгә шалтыраттым. Андагы иптәшләрем, Сашаны (ул вакытта безнең өчене ул Натан түгел, Саша иде) үлем җәзасыннан дөнья җәмәгатьчелеге генә коткарып калды диделәр. Әлбәттә, Саша өчен нык борчылган идек. Әмма Саша-Натаннар демократийәсенең, кеше хокукларының асылына мин соңыннан гына төшендем. Мәскәүгә килеп, үзәк телевиденийедә биргән интервьюсында ул бөтенләй башка нәрсәләр сөйләде. Телеведущийның: «Син бездә кеше хокукларын яклавың белән танылдың, ә Исраилдә карашың үзгәрмәдеме?», - дигән соравына, турыдан-туры: «Кеше хокуклары әйбәт нәрсә, әмма Исраил дәүләте булмаса, мин моның мәгънәсен күрмим», - дигән иде. Димәк Мәскәүдә ул кеше хокуклары өчен түгел, Исраил дәүләте өчен көрәшкән икән. Һәм сүздә түгел, гамәлдә. Үзен үлем куркынычы астына куйып. Шуңа күрә ирек мәсьәләсендә дә аның фикере төгәл. Шул ук әңгәмәдә: «Син үзеңне кайчан иреклерәк сизә идең, төрмәдәме, әллә хакимийәттәме?», - дигән сорауга: «Төрмәдә, анда мин дошманнарыма фикеремне курыкмыйча әйтә ала идем, ә хакимийәттә үзеңне алай ук ирекле тота алмыйсың. Кайвакытта уйлаганыңның киресен сөйлисең. Әмма дәүләтнең югары максатлары өчен ирегеңне чикләргә туры килә», - дип бик ачык итеп җавап биргән иде.

Менә шул ул ирек өчен көрәш үрнәге. Кирәк икән, үлемгә яки зинданга барасың, исән калсаң түрдә утырасың, түрдә утырып та ирегеңне чиклисең. Ә без ирек өчен көрәшергә башкаларны өндибез, аларны зинданга яптырып, дошманның түр башына менеп утырабыз, хакимийәткә үрмәләсәк, чикләрне белмибез. Шуңа күрә йәүрәй дәүләтле, без дәүләтсез, Натан дошман төрмәсендә, без үз төрмәбездә, Натан үз тәхетендә, без дошман тәхетендә. Җитмәсә, шуның белән масаябыз.

Юк, мин монда татарны кимсетү, Исраилне, Натаннарны күтәрү максатын куймыйм. Нийәтем нәкъ киресе. Ирек тә, коллык та ул ике төрле. Берсе аның – илаһи ирек, икенчесе – иблис ирегe. Берсе – Алла, икенчесе – иблис колы. Аллага кол булмыйча, илаһи ирек алып булмый. Бары Аллага буйсыну гына адәмгә һәм малга табынуны бетерә. Киресенчә, иблискә буйсынып кына, иблис ирегe алырга була. Чөнки иблис кенә башкаларны таларга, алдарга, изәргә мөмкинлек бирә. Татар Натаннардан айырмалы буларак, илаһи ирек һәм Алла колы булу, Натаннар исә, иблис ирегe һәм иблис колы булу өчен көрәшә. Әмма татар ирегe өчен көрәшүчеләр саны әлегә бик аз, ә Натаннар ирегe өчен көрәшүчеләр дөнья тулы, шул исәптән татарлар арасында. Безгә һаман да бер гади хакыйкәтне аңларга гыйлемебез җитми: Алласыз бай һәрвакыт хәйерче һәм фани, Аллалы хәйерче

һәрвакыт бай һәм бакый. Хәйерчеләр рух белән бай булырлар дигән Гайсә пәйгамбәр дә. Әмма моны аңлаудан без әле ифрат йырак. Шулай да бүген татарның күпчелеге Натаннар ирерге дауласа да, аның иманлы катламы Батыршалар, Канзафарлар рухы өчен генә булса да илаһи ирек өчен көрәшергә тийеш.

Әмма моның өчен без, беренче чиратта, бөтендөнья көферлегенең исламга каршы алып барган рәхимсез сугышының асылын аңлап, халыкның күзен ачарга тийешбез. Мирза ага Мәхмүдев моңа йүнәлеш бирде инде. Аны куәтләргә генә кирәк. Әйе, бу ифрат кыйын эш. Бөтен дөнья «терророрга» каршы көрәшкәндә, без аларны яклап утырыйкмы? Юк, әлбәттә. Әмма, беренче чиратта, террорчыларның кем икәнлеген ачыкларга тийешбез. Нәкъ шуны бездән йәшерәләр. «Терророрга каршы көрәшергә кирәклеге бәхәссез, - ди Мирза ага да, - тик җәзаны гайеплеләргә бирергә кирәк. Гайеплеләргә!» – дип куәтли ул үзенең сүзен.

Тик кемнәр соң алар террорчылар, экстремистлар, бандитлар? Көфер дөньясы аларны ислам дөньясыннан эзли. «Эзләгән табар», - ди халык. Һәм таба да. Әлбәттә, көфер дөньясының талавына, алдавына, әхлаксызлыгына түзмичә каршы торучы берничә мөселман төркеме эченнән. Ә бит дөньяның бөтен малын, коралын, акчасын, мәгълүмат чараларын туплаган «ирекле» дөньяга аларны бетерү берни тормый. Әмма алай гына түгел икән шул. Алар артында бөтен дөнья мөселманнары тора икән. Димәк, бу төркемнәрне генә түгел, бөтен мөселман дөньясын юк итәргә кирәк. Анысы да әллә ни кыйын эш түгел. Чөнки мөселман дөньясының иблис дәһшәтенә каршы торырлык көче юк. Әмма бар икән шул. Ул да булса, Алла куәте. Чөнки дөньядагы һәр бәндәнең диненә, милләтенә, йәшенә карамастан кальбендә зәгыйфь кенә булса да Алла нуры бар. Шушы нур кешелек дөньясын тулы көферлектән саклый. Моны без беренче чечен-урыс сугышында да күрдек. Ул вакытта көфер дөньясы корал һәм гаскәр белән күпкә көчле булса да, дөньякүләм мәгълүмат кырында оттырды. Мәскәү көферләре чигенергә мәҗбүр булды. Икенче сугышка исә бу яктан да әзерлеклерәк булып килделәр. Көч белән мәгълүмат бер-берсен куәтли алдылар. Башлангыч чорда шулай да әле каршылык булды. Мөселман дөньясы тарафыннан түгел, иманлы насаралар (кальби мөселманнар) тарафыннан. «Свобода» радиосы буйынча чыгыш ясаган бер насара язучысы (исеме истә калмаган), Чечня халкын бетерүне Иса пәйгамбәрне икенче кабат кадаклау дип бәйәләде. Никадәр төгәл чагыштыру. Чөнки Иса пәйгамбәр илаһи хакыйкәтне ачкан өчен үлемгә хөкем ителсә, чечен халкы илаһи гамәл өчен бетерәлә. Ә белорус язучысы Вәсил Быков бу вәхшилеккә Аурупаның битарафлыгын көнбатыш кыйммәтләренең юкка чыгуы белән аңлатты.

Әмма көфер дөньясына мөселман дөньясының куркынычлыгын раслау өчен кешене шаккаттырырлык дәлилләр кирәк иде. Шулай итеп Мәскәү, Волгодонск, Каспийск шартлаулары, Дагыстан парламентына «бәреп керү», чеченнәрнең Дагыстанга «һөҗүм» итүе кебек кире кага алмаслык «дәлилләр» булдырылды. Боларны эшләү нииндидер «вәһһабилар»га йөкләнде. Корал, диверсийәләр, «вәһһабилар», мәглумат чаралары икенче һөҗүмне уңышлырак итте. Әмма таулар ишелеп төшмәде, күк капусы ачылмады, каршылык кимемәде. Димәк бу «дәлилләрне» дөньякүләм дәрәҗәдә исбатларга кирәк иде. 11 сентябрь

вакыйгалары шушы явызлыкның нәтиҗәсе. Бернинди икеләнүсез, коточкыч кансызлык белән Нью-Йорк, Вашингтон фаҗигаләре ясалды. Дөнья өнсез калды. Америка кадәр Американы өркетә алган исламның никадәр куркыныч булуы «расланды». Һәм барысы да Америка ягына авышты. Шул исәптән кайбер ислам илләре дә. Төрки дәүләтләр турында әйтеп торасы да юк. Алар «террорга» каршы көрәштә Американың беренче аркадашлары булдылар. Безнең Рәсәй мөфтиләре дә, «ислам тынычлык дине» дип, «террорны» гайепләргә ашыктылар һәм Мәскәү патшасына тугрылык күрсәттеләр. Әмма бу гына җитмәгән икән. Америка патшасы каршында да акланырга кирәк булды. Тиздән Вашингтонга барып, бөтен рәсми ислам дөньясы көфер дөньясы каршында баш иде. Инде курыкмыйча, бөтен дөнья күләмендә «террорчылыкны» юк итәргә була. Вифлеемдагы Иса пәйгамбәр чиркәвен саклаучы фәлестин-насараларны да кызганмаган кяферләр Мәккәнең Хәрәм мәчете сагында торучы «вәһһаби» мөселманнарны кызганырлармы? Юк, әлбәттә! Әнә бүген үк инде көфер дөньясының мәгълүмат чаралары Американы Согуд Гарәбстанына каршы куярга тырыша. Ике арадагы аркадашлык элемтәләрен бозарга чакыра. Фаҗига корбаннарының «туганнары» Мәккә һәм Мәдинә мөселманнарына триллионлаган доллар күләмендә «зыянны каплауга» дәгъва белдерә. Йәнәсе, әлеге шартлауларны шулар оештырган. Ә бит бу «зыянны» Согуд Гарәбстанының барлык мал-мөлкәтен, бөтен җир асты байлыкларын сатып та каплап булмый. Димәк, мөселман дөньясына мәңгелек коллыкка төшүдән башка чара калмый. Ышансаң ышан, ышанмасаң ышанма, дөньяны тетрәткән 11 сентябрь шартлаулары нәкъ шуның өчен кирәк тә иде.

Әлеге юлларны укыган кеше әйтер, бу Әмирхан дигәннәре бөтенләй саташкан икән, ни өчен Америка кадәр Америка үзенең иң биек, иң бөек, иң бай сәүдә үзәкләрен шартлатсын? Әйе, укучым, ышанырлык нәрсә түгел бу. Хәтта бу вәхши заманда да. Әмма гасыр башында ук Ленинның, «капиталист 300% табыш өчен теләсә нинди җинаять каршында да туктап калмаячак», дип әйткән сүзләрен онытмыйк. Сүз триллионнар, «алтын миллиардның» йәшәү мәгънәсе турында барганда, миллионар белән исәпләнгән зыян чүп кенә бит ул. Илләр, җирләр сатылганда табышсыз манаралар белән санашып тормыйлар.

Хәйер, болар турында Гамил Афзал күптән әйткән иде инде:

«Ярый әле, Галәм бүләргә дип, йолдызларга менә алмыйлар,

Кояш нурын бүлә алмыйлар да, йолдызларны бүлә алмыйлар».

Инде аларын да бүлә башладылар бугай, Гамил ага. Әнә, Айда да инде җир сатарга нийәтлиләр. Көфер нәфесе бит ул Галәмнән дә чиксез.

Аннан шуны да онытмыйк, «алтын бозауга» табынган бу серле-дәһшәтле көчләр каршында иң куәтле дәүләтләрнең дә җитәкчеләре марионетка гына. Кирәк икән тәхеткә утырталар, кирәкми икән, алып ташлыйлар. Без генә аларны дөньяның кендекләре дип саныйбыз. Ә чынында алар балавыз курчагы гына.

Шулай да көфер дөньясына бүген кем яный? Кавказ тарлавыкларында мылтык тагып йөрүче берничә дистә чеченмы, Әфганстан тауларында ачлы-туклы көрәшеп йөрүче талибларммы, нindидер мифик «Әл кагъдә» сугышчыларымы, биленә шартлаткыч аскан бер төркем фәлестинме, Кашмирдагы коралсыз

мөселманмы, йә булмаса тегендә-монда каршылык күрсәтеп торучы үз иленең мөһәҗиреме? Юк, әлбәттә. Әмма болар үзләре зур көчкә ийә булмасалар да, тирән халык катламнарының аңына сеңгән җирдәге коточкыч гаделсезлекне тойымлауның актив халәтен гәүдәләндерәләр. Димәк бу ислам каршылыгы гына түгел, бөтен дөнья изелгән, тапталган, кимсетелгән халыкларның, адәмнәрнең каршылыгы. Әмма кешелекнең 80-85% ын тәшкил иткән бу «массаны» туплар-йәдрәләр белән генә бетерерлек түгел, ул үзлегеннән кырылып бетәргә тийеш. Моның өчен әлеге «массага» карата шушы хөкем карарын тормышка ашырырга комачаулаган «экстремист-террорчыларны» юк итәргә кирәк. Ә ислам нәрсәдә гайепле? Чөнки бу «робин-гудлар» гаделлекне ислам кануннары нигезендә торгызырга тырышалар. Бары ислам мәгәрәләрендә генә әлегә илаһи хакыйкәтләр берникадәр дәрәҗәдә сакланып калган. Әгәр бу хакыйкәтләр бетерелергә тийешле «массаның» мәрткә киткән аңына барып җитсә, халыкның 15-20% ыннан артмаган көфер катламы пыран-заран китереләчәк. Әнә бит Аксенов нәкъ исламны «алтын миллиард» идейәсен «уйлап чыгаруда» гайепли. Ягъни, бу идейәнең киң халык массаларына барып җитүеннән курка. Шуның өчен алар ихлас коммунистлар күтәргән социаль гаделлек идейәсеннән дә кәмит ясадылар. Җәллад Сталин, йүләр Хрущев, маразматик Брежневларга дилбегәне биреп, миллионлаган кешене юлдан яздырдылар. Илне туздырып, «акыллыларын» «алтын» катламга алдылар, «саташканнарын» «масса»га әверелделәр. Яңа дәвер алдыннан Муса галәйһиссәлам, дүртенче гасырда Гайсә пәйгамбәр өммәтләрен шушы юл белән бетерделәр. Исән калганнарны чиркәү астына кертеп дәрвиш иттеләр. Ислам белән дә, нигездә, эш хәл ителгән. Чиркәү мисалында мөфтийәтләр ясап, имамнарга «указ» тоттырып, халыкны «алтынга» һәм «нәҗескә» бүлеп, диннән декорацийә ясадылар. Алла сүзе үтмәс, шәригать үтәлмәс булды. Аларны иблис вәсвәсәсенә корылган «халыкара кануннар» алмаштырды. Әмма айырым «экстремист» төркемнәр әлеге кануннарга буйсынмый, «кеше хокукларын» бозуны дәвам итә. Башта, «массалар» йоклап ятканда, бу «бандитлардан» тиз котылырбыз дип уйладылар. Әмма эш аларча ук җиңел булып чыкмады. «Массаларда» да аз-маз җан калган икән. «Алтын катлам» теләгәнчә, «массалар» да тиз генә боларга үз «бандитларын» тотып бирмәде. Йәшерү ягын карады. Димәк, уяу «массаларны» аракы, әфйүн, фәхеш белән исертеп, мәңге уянмаслык итәргә кирәк. Шулай итеп, әкренләп, сәрхүш «масса» кырыла, «алтын» катлам өскә калка.

Тик әлегә күпчелек «алтын миллиард» барлыгына ышанып бетми. Аксеновлар сүзенә ийәреп, аңа ислам уйдырмасы итеп кенә карый. Әмма бу бик күп рәсми мәгълүматлар белән расланган хакикый чынбарлык. Мирза ага да үз фикерен шуларга таянып дәлилли. Интернеттан алынган соңгы мәгълүматлар буйынча, «алтын миллиардка» кергән халыкларның уртача йыллык кереме 20 мең доллар тәшкил итсә, биш миллиардлы «массаның» кереме бер мең доллардан артмый. Рәсәйдә бу керем дүрт мең доллар чамасы. Шулай да «затлы» катламга бай халыклар гына түгел, ярлы халыкларның да өске катламы керә. Әлбәттә инде, ил никадәр ярлы, «алтын» катлам белән «нәҗес массасы» айырмасы да шулкадәр тирән. Чөнки байларча йәшәр өчен күбрәк таларга кирәк. Шуңа күрә болар чик-

чаманы белми. Байлардан да байырак буласылары килә. «Затлылык» яман шешкә әйләнеп, үз «массасын» ашый. Шул сәбәпле таланган халыклар бергә ойыша алмый. Моңа һәркемнең үз «алтын» катламы киртә булып тора.

Халыкларны «алтын» һәм «нәҗес» катламына бүлү моделе бөтендөнья көфер үзәге тарафыннан уйлап чыгарылган. Бигрәк тә ул ислам йогынтысы зәгыйфь булган илләрдә нык таралган. Яңа Русийәдә дә ул тамыр җәйеп килә. Шуңа күрә бу илләрдә бөлүчеләр, чирлеләр, үлүчеләр саны йылдан-йыл арта. Ислам дөньясы гына әлегә моңа бирешмәскә тырыша. Әмма шәригать кануннарыннан тайпылыш арткан, өске катламның нәфесе үскән сайын мөселман илләре дә аның йогынтысына бирелә бара. Анда да илаһи исламнан тайпылыш сизелә.

Шулай да «алтын миллиардка» кергән халыклар нигә бай һәм «алга киткән», ә кермәгәннәр - ярлы һәм артка калган? Күпләр, тирән уйлап тормыйча, әлеге хәләтне шулай аңлаталар: тегеләр акыллы – болар надан, тегеләр уңган - болар ялкау, тегеләр айык - болар сәрхүш һ.б. Моннан турыдан-туры шундый нәтиҗә ясала - тегеләр кеше, болар хайван. Һәм гаҗәпкә калмагыз, бу нәтиҗә җыһудларның «тәүрәт» һәм талмудларыннан килеп чыга. Алдарак аңа тукталырбыз. Әлегә бер нәрсәне ачыклап китик. Бай һәм ярлы булу нидән килә соң? Акылданмы, уңганлыктанмы, тырышлыктанмы, таланттанмы, осталыктанмы, әллә бүтән нәрсәдәнме? Әйдәгез, көне-төне үз хуҗалыгында эшләүче гади авыл кешесен алыйк. Аның бит шактый гына уңганлыгы һәм тырышлыгы да, азмы-күпме таланты һәм осталыгы да, үзенә җитәрлек кенә булса да акылы да бар. Әмма никадәр тырышмасын, бите белән җир себермәсен, урламыйча, алдамыйча йәшәгәндә әллә ни байып китә алмый. Бары очын-очка ялгап кына йәши. Зур өйләр төзергә, затлы машина алырга, иркенләп ял итәргә башына да килми. Йыллык кереме 20-30 меңнән артмый. Бу да әле утын-суын кисмәсәләр, җиренбасуын алмасалар, печәнен-утынын әзерләргә комачауламасалар, тапкан малын урламасалар, салым белән бөлдермәсәләр. Әле бит корты- коңгызы, җиле-давылы, йүеше-корылыгы бар. Ярар, бу кеше әллә ни укымаган, зур һөнәр үзләштермәгән, зур талантка ийә булмаган ди. Ә менә доктор, профессор дәрәҗәсенә ирешкән намуслы галимнәрне, зур талант ийәсе язучыларны, шагыйрьләрне, сәнгать осталарын алыйк. Аларның да бит йәшәү дәрәҗәсе шушы авыл кешесенекеннән әллә-ни артмый. Ә җәмгыйәтнең бөтен бозыклыгын төзәтергә алынган укытучы-табибларны алыйк. Аллар, гомумән, фәкыйрьлек чигеннән үтә алмый. Аның каравы, укырга да, эшләргә дә теләмичә, укытучыларның үзгенә үткән башкисәрләр, һавадан табыш ясаучы «бизнесменнар», табигатьне талап баючы «эшмәкәрләр», иманын һәм тәнен сатып көн күрүче фәхишәләр, дәүләт имчәген суырып ятучы ришвәтче сәйәсәтчеләр, халык милкен прихватизацийәләгән байбәтчәләр, җәсади нәфесен тыя алмаган надан түмгәк-түрәләр «иномаркаларда» җилдертәләр, «хан сарайлары» салалар, «виллалар» төзиләр, «канарларда» ял итәләр. Менә шушы «алтын» катламга ислам комачаулый да инде. Чөнки ул иблис коткысы белән чылбырдан ычкынган җинайәтчел «чиксезлекне» чикләргә, ийәрләргә тырыша.

Әлбәттә, үз хәләл көче, таланты, осталыгы, сәламәтлеге һәм берникадәр дәрәҗәдә уңучанлыгы аркасында мул тормышта йәшәгән кешеләр бу исәпкә

керми. Алар хәрәмгә йәшәгән бәндәләрдән айырмалы буларак, байлыкны үзмаксат итмиләр, аны саваплы эшкә җигәләр, кешеләргә карата йәрдәмчел, миһербанлы, игътибарлы булалар. Байлык та бит ул, фәкыйрьлек кебек үз колларына карата Алланың сынавы. Бәлки бу сынау катырактадыр. Шуңа күрә сүз монда ярлыны байга, байны ярлыга каршы кую турында түгел, хәләлне хәрәмнән айыру турында бара. Югыйсә, хөсетлек һәм көнчелеккә бирелеп, яңа большевизм, яңа «шариковлар» тудыруыбыз бар. Сүз монда бары тик хәрәмгә корылган җәмгыйәттә «алтын миллиардның» ничек хасил булуы турында бара. Чөнки болар барлык чикләрне үтеп, кешелек дөньясын һәлакәткә этәрә. Моны алар үзләре дә белә, әмма ихлас тәүбәгә киләсе урынга, гайепне илаһи исламнан эзли.

Кайберәүләр «алтын миллиардның» барлыкка килүен җир йөзендә халык саны артуы, табигый байлыкларның кимүе белән акларга тырышалар. Әйе, андый проблемалар да бар. Әмма төп сәбәп анда түгел. Халык саны артса да, фән үсә, яңа технологийәләр барлыкка килә; табигый ресурларның бер төре бетсә, икенче төре барлыкка килә. Ягъни халык саны белән йәшәү ресурслары арасында һәрвакыт ниндидер баланс, көйләнү саклана. Тикмәгә генә һәр бала үз ризыгы белән туа дип әйтмибез. Ә нәрсә җитми соң? Җәмгыйәттәге социаль гаделлек. Һәм иң гаҗәбе шул: байлык арткан сайын тизләнеш белән нәфес үсә. Нәфесне бары тик иман гына йегәрли ала. Ә иман сакчысы булып Алла кануннарына нигезләнгән дин тора. Иман һәм дин булганда иң фәкыйрь җәмгыйәттә дә иминлек саклана. Социаль гаделлек бозылган илләр генә рухи һәм матдәви кризис кичерә. Моны бүгенге Русия мисалында да күрсәтергә була. Кеше башына бу илдә йыллык керем 4 мең доллар чамасы дигән идек. Гаиләдә дүрт кеше булса, бу 16 мең доллар дигән сүз. «Алтын миллирдка» кергән илләр белән чагыштырганда бу әллә ни күп түгел. Ә шулай да бу суммага өч бүлмәле фатир алырга була. Бер йылда. Без исә гомер буйы эшләп тә бер иске фатир ала алмыйча интегәбез. Чөнки безнең фатирларны «алтын» катламның затлы кәттиже ашый. Кеше башына 500 доллар туры килә торган җәмгыйәттә айырма тагы да зур. «Алтын» кеше сарайда йәши, фәкыйрь бәндә урамда ауный. Аның каравы, йыллык керем 32 мең доллар тәшкил иткән Америкада дүрт кешелек гаилә бер йылда безнең үлчәмдәге өч бүлмәле 8 фатирга ийә була ала. Әлбәттә, гаделлек булса. Гаделлек булмаган очракта да, андагы фәкыйрь безнең байга тора. Русийә бик ук бай булмаса да, гаделлек булса без бик әйбәт йәшәр идек. Моны дәлилләү максатыннан Алмаз Миргаязовның «Заман» гәзитендә басылган бер язмасын китерәм: «Тормыш авыр, икътисад баткаклыкта дип зарланабыз. Моның сәбәпләрен, гайепләләрне эзлибез. Ә алгарыш һаман юк. Акча һаман җитми, ә ашыйсы килә. Шулай да җир асты тулы нефть, газ, алтының тулып ятсын да, ашарга булмасын - акылга сыймаслык нәрсә бит бу. Соңгы мәгълуматлар буйынча Рәсәйдә нибары 145 миллион чамасы кеше йәши. Шуларның 29 миллионы балалар, 30 миллионы картлар, 7,4 миллионы эшсезләр һәм 17 миллионы (!) алкоголиклар (исәптәгеләре, әлбәттә). Шул ук вакытта һәр 100 кешегә уртача 12 автомашина туры килә (12 се дә бер кешедә булуы мөмкин). Һәр адәм баласы йылына уртача 58 кг ит, 120 кг икмәк ашый - көненә 160 һәм 320 шәр грамм дигән сүз. Һәр кешенең айлык кереме 2165 сум тирәсе (балаларның

акча эшләмәгәннәрен, картларның пенсийәләре песи ашатырга гына җитүен исәпкә алсак, ике тапкыр күбрәк сумма чыга). Әле шуның өстенә Рәсәйдәге һәр кешенең мендәре астында 690 шар доллары да бар икән. Торак мәйданга килгәндә, кеше башына 19 шар квадрат метр йәшәү урыны туры килә. Моның өстенә һәр кешегә 11,7 га җир, 5,9 га урман, 1,5 га басу, йыл сайын 2,1 тонна нефть һәм 4,1 тонна газ туры килә. Җәмәгать, бу кадәр бай булып та, тормыш авыр дип зарлану килешәме соң?», - ди автор. Димәк, хәйерчелек кеше исәбенә керүдән килә.

Кайберәүләр мине ясалма тигезләүгә (уравниловкага) өнди дип уйлаулары бар. Юк туганнар, мин кешеләрне тигезләүгә өндәмим, тигезлеккә (равенствога) өндим. Тигезләү белән тигезлек икесе ике нәрсә. Беренчесе аның ялкауга куәт, икенчесе – социаль гаделлек (социальная справедливость). Әмма күпчелек моны буш хыялга (утопийәгә) саный. Әнә, диләр, социалистлар, коммунистлар моны эшләп карады бит инде. Шуннан нәрсә килеп чыкты? Нәкъ киресе. Мондый фикерләү иң бөйек идейәләр белән дә ришвәти уйнауның аяныч нәтиҗәсе.

Бу тискәре нәтиҗәләрнең сәбәбе нидә? Беренче – ихлас коммунистлар социаль гаделлекне тигезләүгә кайтарып калдырдылар һәм әрәмтамакларны тудырдылар. Икенче - социаль гаделлек идейәсен диннән айырдылар һәм Алла каршында җаваплылыкны бетерделәр. Өченче - Алладан курыкмау мөнафикълыкка китерде һәм тоташ ришвәтчелек тудырды. Башлары зинданнан чыкмаган намуслы кампанеллалардан башланган илаһи омтылыш ришвәти «брежневчылык» белән тәмамланды. Бүген исә соңгыларның «элитный» варислары «алтын миллиард» катламына килеп кушылды. Шуны тойымлаган илаһи бәндәләр җәмгыйәтне дин юлына өндәде. Әмма монда да «брежневчылык» өскә чыкты. Чөнки социаль ихласлык белән бергә дини ихласлыкның да тамырлары киселгән иде. Шундый ук хәл ихлас милләтчелек белән дә кабатданды. Шулай итеп җәмгыйщт тулысы белән «алтын» һәм «нәҗес» катламнарына бүленде. Һәм моны ихлас динчеләр, ихлас милләтчеләр, ихлас социалистлар түгел, ришвәти динчеләр, ришвәти милләтчеләр, ришвәти социалистлар эшләде. Димәк, «алтын миллиард» идейәсе ихлас исламчылардан түгел, ришвәтче иблисчеләрдән чыга.

Инде бу идейәнең асыл (гносеологик) тамырларына төшеп карыйк. Иң беренче үзебезгә шундый сорауны куйыйк. Нишләп бу идейә дөньякүләм йогынтыга ийә? Нигә аңа иң ихлас кешеләр дә каба? Ник Алла дине дә аңа каршы тора алмый? Әллә иблис мәлгунь Алладан да көчлеме? Тирәнгәрәк төшә башласаң әллә нинди гонаһлы уйлар килә. Әмма сабыр итик.

Алдарак әйткәнемчә, «алтын» халык идейәсе «Алла сайлаган милләт»нең «тәүрәт»енә салынган. Вавилон һәм Кодус талмудларында ул гамәлләштерелгән. Дәһри (атеист), мөшрик (мәҗүси), яки диннең илаһи асылын аңламаган кешегә моның әһәмийәте юк. Алар күптән инде «алтын» халык өчен чимал, ашлама, тауар вазыйфасын үти. Тик үзләре моны белми. Шулар колы булсалар да, Алла колы булуны түбәнлеккә саныйлар. Әмма диннең илаһи асылын аңлаган, бер Аллага гына табынган диндар өчен бу ифрат мөһим мәсьәлә. Чөнки «тәүрәт» һәм талмуд буйынча «Алла сайлаган халык» исәбенә кермәгән бәндә «гой», яки мәхлук, гади телгә күчерсәң, хайван санала. Ягъни, андый бәндә хайван хокукына гына ийә.

Әйе, аны да ашаталар, эчертәләр, өйрәтәләр, дәвалыйлар, торыр урын бирәләр, күңел ятса иркәлиләр, юлга чыгарга кирәк булса - җигәләр, ашарга кирәк булса - бугазлыйлар, кийәргә кирәк булса - туныйлар, сакларга кирәк булса – өрдерәләр, буйсынудан чыкса – типкәлиләр, кирәге калмагач – куалар. Ә иң гаҗәбе, боларны зур дәрәҗәгә санап, хуҗасына  эт тугрылыгы күрсәтеп, «гой» «үз теләге» белән эшли. Хуҗа вазыйфасын, әлбәттә, «алтын» халык яки аның «көтүчеләре» үти.

Шулай да мондый «илаһи» бүленешнең нигезе һәм асылы нидә? Нигә күрә торып кеше шуңа риза? Чөнки ул диннең илаһи асылын белми. Аның өчен, нигездә, дин ул – мәчет-чиркәү, мулла-поп, тәре-шамаил, ярымай-хач, вәгазь-дога, чалма-чикмән, түбәтәй-яулык һ.б.  Шуларның уңай яки тискәре тәэсирен тойып, ул йә динле, йә динсез, йә мөшрик, йә мөнафикъ  була. Күпчелек исә, «өсләр», яки «алтын катлам» хуплаган идеологийәгә ийәрә. Шунда инде бөтен фаҗига да. Кеше үз ихтыяры белән илаһи хакыйкәткә турыдан-туры чыга алмый. Иманы зәгыйфь булганга көфер дөньясы киртәләгән нурга тоташырга үзендә көч-ихтыяр тапмый. Йәрдәм кулы сузарга теләүчеләрне дә күрми, танымый.

Ә чынлыкта исә, дөнья яратылганнан бирле бер Алла дине хөкем сөрә. Адәм баласы да мәхлукат буларак милләтенә, заманына карамастан, шул дингә буйсынып йәшәргә тийеш. Шуңа буйсынмаган бәндә кяфер яки «гой» санала, әйткәнебезчә, хайван хокукында йөри. Асылда бу шулай булырга тийеш тә. Чөнки Алланы танымаган, Аңа буйсынмаган кеше тәмуг ийәсе. Нәкъ шушы илаһи хакыйкәттән ришвәти рәвештә файдаланып, җыһудлар үзләрен Алла кешеләре, башкаларны аларга буйсынырга тийешле «гой» дип саныйлар.  Шуның өчен алар Муса г.с. китергән Тәүрәтне үзгәртеп, кешелек тарихын яңабаштан язалар. Хәтта календарьне дә «дөнья яратылганнан башлап» алып баралар. Йәнәсе, кешелек тарихы җыһудлардан башлана. Шуңа күрә яңартылган «тәүрәттә» барлык пәйгамбәрләр дә, Адәм г.с. башлап, Муса г.с. кадәр җыһудлар. Әлбәттә, Муса г.с.нән соң килгән пәйгамбәрләр моны инкарь итәләр. Шуның өчен Гайсә пәйгамбәр җыһудларның иң югары дини мәхкамәсе (синедрион) тарафыннан хачта кадакланырга хөкем ителә, ә аннан соң килгән Мохаммәд г.с.нең пәйгамбәрлеге танылмый. Гайсә һәм Мохаммәд г.с.нәргә ийәргән халыклар «Алла кануннарыннан» (Тәүрәттән) тайпылуда гайепләнеп «гой»га әвереләләр.

Шулай да, җыһудлар берничә миллионнан артмаса да, каян килгән соң ул «алтын миллиард»? «Гойлар» исәбенәме? Ә нигә аларның бер өлешенә мондый хокук бирелгән? Нәкъ бөтен хикмәт тә шунда. Чөнки Тәүрәт бозылган кебек үк, «йәһүд» төшенчәсе дә бозылган. Ул җыһуд (жид) атамасына әйләнгән.

Кемнәр соң алар йәһүдләр? Йәһүд төшенчәсе белән җыһуд  аңлатмасы нәрсә белән айырыла? Моңа ачыклык кертмичә, без «алтын миллиардның» асылын аңламаячакбыз. Шуңа күрә  «йәһүд» төшенчәсенең  мәгънәсенә тирәнрәк керик.

Татар телендә «йәһүд» һәм «йәһүди» сүзләре этник һәм дини төшенчәләрне белдерә. Тарихи күзлектән караганда, бу дөрес. Әмма бүген бу дөрес түгел. Җыһудлар әле дә шундый аңлатма ягында.  Чөнки бу очракта җыһудка каршы баручыларны «антисимитизмда» гайепләп, җавапка тартырга була. Асылда исә, бүгенге «йәһүд» атамасы этник төшенчә дә, дини төшенчә дә түгел, ә көфер

төшенчәсе. Эш шунда ки, борынгы йәһүд белән хәзерге йәһүд икесе ике нәрсә.

Башта йәүрәй (еврей) һәм йәһүди (иудей) төшенчеләренә аңлатма бирик. «Йәүрәй» сүзе чыгышы (этимологийәсе) ягыннан семит телләре канунчылыгы буйынча иврим, иврит, Ибраһим (Авраам) төшенчәләренә тиңдәш. Ягъни, бу сүз Ибраһим г.с. балалары дигән мәгънәне аңлата. Шулай булгач, ул бүгенге йәүрәйләргә генә түгел, барлык симит, шул исәптән гарәп һәм фәлестиннәргә дә кагыла. Әмма Рим яуларыннан соң латин телләре канунчылыгы нигезендә «иврим» сүзе йәүрәй (еврей) сүзенә әйләнә. Бу атама соңга таба нәсара һәм ислам дине кабул итмәгән ивримнарга гына берегеп кала. Чөнки нәкъ алар күчмә тормыш белән йәшәгән бедуиннардан айырмалы буларак Исраил халкының төп шивәсен тәшкил итәләр дип санала. Бу күренешне «татар» атамасы белән чагыштырып була. Алтын Урда мәмләкәтендә барлык халыклар да этник яктан анык булмаган «татар» атамасы белән йөри. Урда таркалгач, бу атама инде этноним рәвешендә Казан һәм Кырым татарларына (дөресрәге, болгарларына) гына берегеп кала. Чөнки алар бу мәмләкәтнең дәүләти нигезен тәшкил итәләр. Бүгенге «урыс» атамасы да этник асылыннан йырак тора. Ул, башлыча, этник яктан төрле булган халыкларны ассимиляцияйә вазыйфасын үти. Рәсәй мәмләкәте таркалган очракта бу атама дәүләткә исем бирүче Мәскәү урысларына гына берегеп калачак.

